ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Постановление　　　　　　　　　　　　Карар

“22” декабря 2017 г.　　　　　　　　　№ 19

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән теререкөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән теререкөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны урнаштыру түбәндәгечә башкарыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Омар авылы, Мәктәп урамы, 18 йорт;

2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы Березовка поселогы, Үзәк урамы,12 йорт;

3. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Вандовка авылы, Приречная урамы, 9 йорт,;

4. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Югары Сикәнәс авылы, Совет урамы, 23 йорт;

5. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Кулуш-Пустошь авылы, Кызыл Армия урамы, 1 йорт;

6. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Сикәнәс авылы, Мәктәп урамы, 45 йорт;

7. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Рагозино авылы, Яңа урамы, 12 йорт;

8. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Омар Пүчинкәсе авылы, Көньяк урамы, 18 йорт;

9. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Яңавыл авылы, Кама буе урамы, 1 йорт;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарында урнаштырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /Н.П.Князева/

Татарстан  Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге
Башкарма комитетының
22.12.2017 ел, 17 нче санлы карарына
кушымта

**Исемлек**
**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары**

| № | Кулланылган сымап лампаларын беренчел җыю һәм урнаштыру урыны адресы |
|---|---|
| 1. | 422183, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Рагозино авылы, Яңа ур., 12 (ярдәмче бина). |